**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«25» 03 2020 ел Яр Чаллы №21

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында «Сосновый бор» коммерциясез бакчачылык ширкәтендә торак йортлар. Газ белән тәэмин итү» капиталь төзелеш линия объектын планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елнын 28 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезнамәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында «Сосновый бор» коммерциясез бакчачылык ширкәтендә торак йортлар. Газ белән тәэмин итү» капиталь төзелеш линия объектын планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Халык тыңлауларын бер көндә, 2020 елның 28 апрелендә 18.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай районы, Кече Шилнә авыл җирлеге, Олы Шилнә авылы, Киров урамы, 55.
3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Л.Г. Авзаловны билгеләргә.
4. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашу тәртибен кушымтадагыча расларга.
6. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров